# ИМАНЛЫ ГАИЛӘ

Гаилә тормышын яктыртучы дини-мәгърифәти газета

№1
МАРТ
2012


**Газетада Коръән аятьләре булу сәбәпле, саклык белән куллануыгызны сорыйбыз.**

## АНОНС

*Гаилә—ул бер дәүләт.*



2 бит

Рәис хәзрәт МӨБАРӘКШИН

**Ир белән хатын хакы**

4 бит

Наилә ҖИҺАНШИНА:

**“Бер-береңә булган ышаныч мәхәббәтне арттыра”**



5 бит

Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ

**Никахлы гаилә таркалмас**



7 бит

**Ислам диненә мәхәббәт тәрбиялик**



## *Хәерле сәгатьтә!*

***Әгуузу билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдулилләәһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәту уәссәләәму гәләә расуулинә Мухәммәдиу уә гәләә әәлиһи уә әсхәәбиһи әҗмәгииин. Әссәләәмугәләйкум уә рахмәтуллааһи уә бәракәәтуһ.***

***Хөрмәтле мөселман кардәшем!***

***Син "Иманлы Гаилә" газетасының беренче санын кулыңа алдың. Газеталар күп булса да, тулаем гаилә проблемаларын киң яктыртканнары сирәк. Көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән гаиләңә игътибарың кимемәдеме икән, ирең яки хатының, балаларың һәм якыннарыңның хәле белән кызыксынасыңмы? Алар ни көтә синнән? "Иманлы Гаилә" газетасын укыгач, шушылар хакында да уйлап кара әле.***

***Халык: "Мәхәббәт булса, калганы була аның",—ди. Шулай, әлбәттә. Ләкин һәлак булган мәхәббәтләр, корылып та җитмичә таркалган гаиләләр юкмыни? Гаилә традицияләрен ничек сакларга? Гаиләдә ничек итеп яхшы, җылы мөнәсәбәтләр, шартлар тудырырга? Ничек итеп көндәлек гаилә тормышында бәхет кояшының сүнүенә юл куймаска?***

***Гаилә тормышы—үзе бер гыйлем ул. Әгәр без кыен хәлдә калган гаиләләргә булыша алсак, яшь гаиләләрнең киләчәк бәхетле тормышларын төзүдә аңлату эшләре белән ярдәм итә алсак, Ислам дине аша аларны тәрбияли алсак, оешмабыз үзенең максатына иреште дип санар идем.***

***Гаилә—бер-берсен яраткан кешеләрнең бергә яшәүләре генә түгел. Ул—ир белән хатын, әти-әни һәм балалар арасындагы мәхәббәтне саклаучы бердәнбер урын. Гаилә тыныч булса, кеше өендә рәхәтләнеп ял итә, җанын сафландыра, алдагы көнгә көч туплый. Бары гаиләдә генә балага әхлак нигезләре салына. Ислам дине кануннарына таянып әйтә алам: бары Ислам динендә генә туры юл, изге гамәлләр һәм барлык сорауларга җавап.***

***Безгә ничек тә уңышсыз гаиләләр булмауга ирешергә кирәк, чөнки алар җәмгыятьнең үсешен тоткарлыйлар. Нык төзелгән гаилә генә җәмгыятьтә тормыш атмосферасын, климатын яхшырта ала. Әгәр без башка кешеләргә дә үзебезгә караган кебек карасак, көн саен һәм ихлас күңелдән башкаларга һәм үзебезгә дә бәхет китерергә тырышсак, моңа ирешербез дип уйлыйм.***

***Бергә булыйк, бердәм булыйк!***

**Рафаэль ӘФЛӘТУНОВ.**
**"Гаилә" Ислам-Мәдәни үзәге Президенты.**

## МАРТ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Милади 2012 ел | Көн исеме | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы | Һиҗри 1433 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Пән | 06:04 | 07:34 | 12:56 | 13:02 | 16:33 | 18:18 | 19:48 | 8 | РАБИГ ӘЛ-АХИР |
| 2 | Җом | 06:02 | 07:32 | 12:56 | 13:02 | 16:34 | 18:20 | 19:50 | 9 | |
| 3 | Шим | 05:59 | 07:29 | 12:56 | 13:02 | 16:36 | 18:23 | 19:53 | 10 | |
| 4 | Якш | 05:57 | 07:27 | 12:56 | 13:02 | 16:37 | 18:25 | 19:55 | 11 | |
| 5 | Дүш | 05:54 | 07:24 | 12:55 | 13:02 | 16:39 | 18:27 | 19:57 | 12 | |
| 6 | Сиш | 05:52 | 07:22 | 12:55 | 13:02 | 16:40 | 18:29 | 19:59 | 13 | |
| 7 | Чәр | 05:49 | 07:19 | 12:55 | 13:02 | 16:41 | 18:31 | 20:01 | 14 | |
| 8 | Пән | 05:46 | 07:16 | 12:55 | 13:02 | 16:43 | 18:33 | 20:03 | 15 | |
| 9 | Җом | 05:44 | 07:14 | 12:54 | 13:02 | 16:44 | 18:35 | 20:05 | 16 | |
| 10 | Шим | 05:41 | 07:11 | 12:54 | 13:02 | 16:45 | 18:37 | 20:07 | 17 | |
| 11 | Якш | 05:39 | 07:09 | 12:54 | 13:02 | 16:47 | 18:39 | 20:09 | 18 | |
| 12 | Дүш | 05:36 | 07:06 | 12:53 | 13:02 | 16:48 | 18:41 | 20:11 | 19 | |
| 13 | Сиш | 05:33 | 07:03 | 12:53 | 13:02 | 16:49 | 18:43 | 20:13 | 20 | |
| 14 | Чәр | 05:31 | 07:01 | 12:53 | 13:02 | 16:51 | 18:46 | 20:16 | 21 | |
| 15 | Пән | 05:28 | 06:58 | 12:53 | 13:02 | 16:53 | 18:48 | 20:18 | 22 | |
| 16 | Җом | 05:26 | 06:56 | 12:52 | 13:02 | 16:54 | 18:50 | 20:20 | 23 | |
| 17 | Шим | 05:23 | 06:53 | 12:52 | 13:02 | 16:55 | 18:52 | 20:22 | 24 | |
| 18 | Якш | 05:20 | 06:50 | 12:52 | 13:02 | 16:57 | 18:54 | 20:24 | 25 | |
| 19 | Дүш | 05:18 | 06:48 | 12:51 | 13:02 | 16:58 | 18:56 | 20:26 | 26 | |
| 20 | Сиш | 05:15 | 06:45 | 12:51 | 13:02 | 16:59 | 18:58 | 20:28 | 27 | |
| 21 | Чәр | 05:12 | 06:42 | 12:51 | 13:02 | 17:01 | 19:00 | 20:30 | 28 | |
| 22 | Пән | 05:10 | 06:40 | 12:51 | 13:02 | 17:02 | 19:02 | 20:32 | 29 | |
| 23 | Җом | 05:07 | 06:37 | 12:50 | 13:02 | 17:03 | 19:04 | 20:34 | 1 | ҖӨМӘД ӘЛ-ӘҮВӘЛ |
| 24 | Шим | 05:04 | 06:34 | 12:50 | 13:02 | 17:05 | 19:06 | 20:36 | 2 | |
| 25 | Якш | 05:02 | 06:32 | 12:50 | 13:02 | 17:06 | 19:08 | 20:38 | 3 | |
| 26 | Дүш | 04:59 | 06:29 | 12:49 | 13:02 | 17:07 | 19:10 | 20:40 | 4 | |
| 27 | Сиш | 04:57 | 06:27 | 12:49 | 13:02 | 17:09 | 19:12 | 20:42 | 5 | |
| 28 | Чәр | 04:54 | 06:24 | 12:49 | 13:02 | 17:10 | 19:14 | 20:44 | 6 | |
| 29 | Пән | 04:51 | 06:21 | 12:48 | 13:02 | 17:11 | 19:16 | 20:46 | 7 | |
| 30 | Җом | 04:49 | 06:19 | 12:48 | 13:02 | 17:13 | 19:18 | 20:48 | 8 | |
| 31 | Шим | 04:46 | 06:16 | 12:48 | 13:02 | 17:14 | 19:20 | 20:50 | 9 | |



***Рәис хәзрәт***
**МӨБАРӘКШИН**

# ИР БЕЛӘН ХАТЫН ХАКЫ

*Менә берничә атна инде, Фатыйма төннәрен йоклый алмый. Ире Галинең үзенә игътибар итмәве, суынуы борчый аны. Ничек кенә тырышып карамады хатын: тәмледән-тәмле ризыклар да әзерләде, кичләрен урын җәйгәндә аеруча назлы булырга тырышып, хәтта ире кайтышына матур итеп киенеп-бизәнеп куярга да вакытын кызганмады. Тик барысы да заяга булды. Гали эшеннән арып кайта да, ашап-эчеп алгач, бераз телевизор карый һәм... йоклап та китә. Тегеләй итеп карады хатын, болай итеп карады, тик Гали аның төртмәле сүзләренә дә, сораулы карашларына да игътибар итмәде. Түзмәде Фатыйма, беркөн бергәләшеп иртәнге намазны укыганнан соң, иреннән турыдан-туры:*

—Гали! Нишләп син соңгы вакытта миңа бер дә игътибар итмисең, минем белән йокламыйсың? Мин бит синең хатының,—дип сорады.

Гали ачуы килеп:

—Син, хатын, ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы? Миңа сине һәм синең балаларыңны яшәргә урын, ашарга ризык, кияргә кием белән тәэмин итү бурычы йөкләнгән, шуннан башканы таләп итәргә хакың юк,—дип җавап кайтаргач, Фатыйма аптырап калды.

Бәлки ул чынлап та иреннән артыгын таләп итәдер? Озак уйлагач: "Бу хакта Галимә абыстайдан сорарга кирәк",—дигән фикер туды. "Аның ире дә мулла. Галимә абыстай үзе дә акылы һәм гыйлеме белән дәрәҗә яулаган, мәртәбәле кеше",—дип уйлады хатын.

Фатыйма килгәндә, абыстай Коръән укып утыра иде, хатын аны сабыр гына көтәргә булды. Галимә абыстай, озаклап дога кылганнан соң, Фатыйманы тыңлады, шундый сорау белән аның янына килүен хуплады.

—Аллаһыга рәхмәтебез булсын!—дип башлады ул сүзен.—Ир белән хатын арасындагы никах, аның шартлары хакында Коръәни Кәримдә ачык итеп әйтелгән. Ир хатынын якларга, яратырга тиеш—никахның төп шарты бу. Никахлы хатынга башка ир орынырга да тиеш түгел. Никахлы килеш башка иргә кияүгә чыгу да тыела. Шуңа да хатын иреннән генә яратылырга тиеш. Әгәр инде ир хатыны белән йокламый, аны читкә кага икән, хатын аерылуны таләп итәргә хаклы. Кайбер Фикһ галимнәре төгәл итеп: "Ир ким дигәндә дүрт төнгә бер хатыны янында кунарга тиеш",—диләр. Әгәр дә ир дүрт ай буе хатыны янында кунмый икән, ул "мулий" була (гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, үзенең гамәлен төзәтергә яки аерылышу өчен ризалык бирергә тиешле кеше). Хатынның ире белән йоклыйсы килүе—табигый хәл. Моны табигать шулай куша һәм дин дә хуплый. Ире аның белән йокламаса, хатын ни эшләргә тиеш соң? Зина кылсынмыни? Аллам сакласын! "Сыер" сүрәсенең 228нче аятендә: "Хатыннарның ирләре өстендә хаклары бар, ирләрнең хатыннары өстендә хаклары булган кебек",—диелгән. Тирә-юнебездә кешене акылдан яздыручы, бәндәләрнең күңелен бозуга корылган тамашалар күп бит. Боларның барысы да нәзберек җаннарга, шул исәптән хатыннар күңеленә вәсвәсә кертергә мөмкиннәр. Менә шуңа күрә ир хатынга тиешле игътибарын киметмәскә, хатын да иренә җитәрлек назын бирергә бурычлы.

Фатыйма абыстайны бик игътибар белән тыңлады һәм тынычланып китте. Абыстай да аны аңлады һәм моңсу күзле хатынның оялып бирми калган сорауларына да җавап әйтергә тырышты. Фатыйманың башында бер сорау бөтерелә иде.

—Ир белән хатынга барысы да рөхсәт ителәме яки тыюлар да бармы?—дип сорарга җөрьәт итте ул.

*Дәвамы бар.*

# Дин юлындагы кешенең ялгышлыклары өчен дин гаепле түгел

*Бер имам хакында бәян*

Бер гарәп Америкага яшәргә күчеп килә һәм, Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итәргә теләп, мәчеткә имам булып урнаша. Берничә ел буе һәр көнне мәчеткә автобус белән йөри ул. Көн саен бер үк вакытта, бер үк урында тукталышта басып торучы бу ирне автобус йөртүче дә таный башлый. Бүтән пассажирлар арасыннан баш һәм өс киеме белән генә түгел, гел елмаюлы йөзе, тәртипле булуы өстенә, сакалы белән дә аерылып торучы бу ирнең мәчетнең имамы булуына төшенгән иде ул. Ислам дине хакында каршылыклы фикерләр ишеткән булуына карамастан, ул бу кеше белән кызыксына башлый. Сәбәбе дә була. Берничә ел элек христиан дине белән кызыксынып, чиркәүгә йөри башлаган була автобус йөртүче. Әмма, чиркәүдәге кайбер дин әһелләренең акчаны артык яратуларын күреп, күңеле кайта. Чиркәүгә йөрми башласа да, ул яшәүнең мәгънәсе нидә булуын аңларга тырышудан өметен өзми. “Ни өчен дөньяга килдем икән мин?”—дигән сорауга җавап эзли. Менә шул сорауларга җавап табарга өметләнеп, Ислам диненнән өйрәнергә тели ул. Бу теләге бигрәк тә, шушы ирне—мәчетнең имамын күргәч көчәя. Әмма, сөйләшергә җай чыкмау сәбәпле, аралашу көн саен кичектерелә бара.

Көннәрдән беркөнне автобус йөртүче имамны сынап карарга тели: билет сатып алган акчаны юри артык кайтара. Имам урынына барып утыргач, үзенә артык акча бирелгәнен аңлый. “Билет бәясе арзанайганмы, әллә автобус йөртүче ялгышканмы?” Имамның башына килгән беренче уе шул була. Аннан: “Әй, ярар, күп акча түгел әле”,—дип, акчаны билет белән бергә кесәсенә салып куя. Шулай да бу акча тынычлыгын ала аның. Нәрсәгә алай эшләде инде? Мәчет тукталышына барып җиткәнче шушы уй тынгылык бирми иргә. “Нигә борчылам соң? Автобус йөртүче бу хакта уйламыйдыр да”,—дип, үзен битәрләп тә ала әле.

Мәчет тукталышы. Ишектән чыгам дигәндә генә, имам:

—Гафу итегез, сез акчаны артык биргән идегез. Билет арзанайдымы, әллә ялгыштыгызмы?—дип сорап куя.


Автобус йөртүче тыныч һәм канәгать тавыш белән:

—Барысы да дөрес. Мин сезне күптән күзәтәм инде. Чөнки мин сез тоткан дин белән кызыксынам. Сезнең аша Ислам диненнән тикшерергә теләгән идем. Дөрестән дә чиста дин микән, шуны беләсем килде. Барыгыз, мин сезнең янга киләм әле, шунда миңа барысын да өйрәтерсез,—ди.

Имамга каз тәннәре чыга, күзләре яшьләнә һәм, коты алынып, автобустан төшүгә җиргә иелеп Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтен белдерә, “динемне сата яздым” дип үкенә, тәүбәгә килеп, Аның кичерүен сорый.

Хөрмәтле газета укучыларыбыз! Һәрчак исегездә тотыгыз: кешенең әхлагына карап, дине хакында фикер йөртәләр. Бу дөрес гамәл булмаса да, шулай эшлиләр. Дин юлындагы кешенең ялгышлыклары өчен дин гаепле түгел. Әмма һәр кеше шуны онытмасын иде: ул үз диненең бер вәкиле һәм һәр кеше үзенең дине өчен сыналырга мөмкин.

# ИЗГЕ КИТАП



**Коръән**—ул адәм балаларын туры юлга өндәргә дип, фани дөньяда кылган гөнаһлары өчен бәндәләрне Аллаһның җәзасы белән курkытыр өчен, соңыннан, аһ, ник без игелек кылмадык икән, игелек кылган булсак, бу газапларны күрмәс идек, дип үкенмәсеннәр өчен, алдан ук кисәтеп кую максаты белән Аллаһ тарафыннан Пәйгамбәргә индерелгән изге Китап.

**Коръән**—кешеләрне җаһилият караңгылыгыннан иман нурына чыгарсын, ширек, җаһилият, гаделсезлек һәм яманлыктан коткарсын өчен Пәйгамбәребез галәйһиссәләм калебенә Аллаһы Тәгалә индергән китап.

**Коръән**—Аллаһның бердәнбер Аллаһ икәнен белсеннәр өчен һәм зиһенле кешеләр уйлап-аңлап, үгет алсыннар дип кешеләргә индерелгән белем Китабы.

**Коръән**—ул маҗаралы, могҗизалы, гыйбрәтле хикәятләр тупланмасы.

**Коръән**—ул дөрес яшәр өчен кагыйдәләр китабы, кешелекнең Төп Законы.

**Коръән**—ул гадел яшәү ысулы, тормыш итү рәвеше.

**Коръән**—ул гүзәл әхлакка, пакьлеккә, сафлыкка өндәүче.

**Коръән**—изге китапларның иң соңгысы.

**Коръән**—күпходалыкка, мәҗүсилеккә, потларга табынучыларга каршы көрәш коралы да.

Коръәнне индерү сәбәпләренең берсе—аны укыган, өйрәнгән, аятьләренең мәгънәсе хакында фикер йөрткән, кануннары буенча гомер иткән, вәгазьнәсыйхәтләреннән файда тапкан кешеләргә Аллаһыга якынаерга мөмкинлек бирү. Мөхәммәт галәйһиссәләм әйткән: “Өйләрегездә Коръәнне мөмкин кадәр күбрәк укыгыз! Чөнки Коръән укылмаган өйдә яктылык аз, яманлык күп була һәм анда күңелсез, борчулы яшиләр”. Коръән укуның никадәр әһәмиятле икәнен аңлату өчен, мөгаен, шушы хәдис җитәдер. Шулай ук: “Коръәнне укыгыз, чөнки ул Кыямәт көнендә үзен укучыларга шәфәгатьле булып килә! Коръәнне оста укучы кеше хөрмәтле затлар белән бергә булыр. Укуы авыр булып, кат-кат кабатлап укучыга икеләтә савап ирешер”,—дигән.

Аллаһ Раббыбыз Коръәнне кешеләргә туры юлны күрсәтер өчен, хакыйкатьне ялганнан аерып, дөрес итеп яшәү өчен индерде. Без Коръән аятьләре белән вәгазьләнеп, нәрсәнең хәләл, нәрсәнең хәрәм икәнен, нәрсәнең фарыз икәнен белеп һәм тормышыбызда Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан сакланыптыелып яшәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә шушы бер мизгел генә булган дөньяда иманыбызны юлдаш итеп яшәргә насыйп итсә иде.

Коръәнне өйрәнгән, укыган, тыңлаган, аның кануннары буенча яшәргә тырышкан һәр мөэмин-мөселманга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм мәгъфирате насыйп булса иде. Амин!

***Сәламәтлек—иң зур нигъмәт***

# “АЛЛАҺ” сүзенең илаһи тәэсире



Иң яхшы һәм нәтиҗәле дәваларның берсе—Аллаһының шифалы сүзләре—Коръәни Кәрим. Шәригатьтә Коръәннең төрле психик һәм физик авыруларга карата иң нәтиҗәле дәва булуы расланган. Берничә ел элек Нидерланд психологы профессор Ван дер Ховен да Коръәни Кәримне уку һәм “Аллаһ” сүзен кабатлау вакытында тап булган ачышын хәбәр итте.

Профессор үзенең ачышын өч ел буена күп кенә кешеләр өстендә алып барган тирән эзләнүләр тәҗрибәсе белән раслый. Аның бөтен пациентлары да мөселман булмый, күпләре исә гарәпчә бер сүз дә белми. Аларга “Аллаһ” сүзен дөрес итеп әйтергә өйрәтәләр. Нәтиҗә искиткеч була. Бигрәк тә, төшенкелеккә бирелү һәм психик киеренкелек белән җәфа чигүчеләр уңай нәтиҗә алалар.

Психолог Ван дер Ховен болай ди: “Коръәнне гарәпчә даими укучылар һәртөрле психик авырулардан имин булалар. Чөнки анда “Аллаһ” сүзе күп мәртәбә кабатлана”. Ул “Аллаһ” сүзендәге һәр хәрефнең психик авыруларны дәвалаганда уйнаган ролен аңлата. Мәсәлән, “һәмзә” белән “әлиф” сулышны контрольдә тотып, сулыш юлының эшчәнлеген яхшырта. “Ләм” сулышны җиңеләйтә. “Һә” үпкә белән йөрәкне тоташтыра, бу үз чиратында йөрәк тибешен тәртипкә сала.

Бу ачыштагы иң кызыклы факт шул—Ван дер Ховен мөселман түгел.

Аллаһыга мактаулар булсын, Ул Үзенең серләрен кемгә теләсә, шуңа ача: “Аллаһы Тәгалә хикмәтен теләгән кешесенә бирер. Кемгә хикмәт бирелсә, ул кешегә Аллаһы Тәгаләдән күп хәерләр бирелде”. (“Бәкара” сүрәсе: 269 нчы аять)

**Никах... Нәрсә соң ул никах? Никахсыз яшәп булмыймы? Юк икән шул. Никах—ант, вәгъдә дигән сүз, саваплы эш. Никах табыны—Аллаһы Тәгалә каршында иң саваплы табыннарның берсе. Монда бирелгән сәдакалар әҗере, кайгылы вакытта бирелгән сәдакаларның әҗеренә караганда йөз мәртәбә саваплырак. Шушы савапларны аңламыйча, кадерен белмичә гаиләләр нигә таркала, балалар ятим кала? "Нигә?" дигән сорауларның барысына да җавап бирә алырлык кеше—Татарстан мөслимәләре берлеге рәисе, Гаилә кору һәм саклап калу үзәге җитәкчесе Наилә Җиһаншина бүген безнең кунакханәбез түрендә.**

## Наилә ҖИҺАНШИНА:

# "БЕР-БЕРЕҢӘ БУЛГАН ЫШАНЫЧ МӘХӘББӘТНЕ АРТТЫРА"

***—Элек аерылышулар булмаган диярлек, хәзер нигә күп икән соң, Наилә ханым? Кавышучылардан бигрәк аерылышучылар саны күбрәк бит.***

—Элек тәрбия икенче төрле булган. Хатын-кызны ирен хөрмәт итеп, итагать итеп яшәргә өйрәтеп үстергәннәр. "Иреңнең кадерен бел, аның күңелен шат кыл, иреңне тәрбияләп яшә",—дип кызына киңәш биргән берәр әни бар микән хәзер? Киресенчә, кызны кияүгә биргәндә тыңлаучан, күп акча эшли торган, күндәм ир эзлиләр.

Аерылышу өчен сәбәпне эзләсәң, һәрчак табыла. Менә бер мисал. Күптән түгел безгә бер апа килеп: "Кияү агы кызымны пропискага кертми",—дип зарланды. Ике гаилә дә шәһәрдә яши. Бу ана өч бүлмәле фатирда ялгызы гомер итә. Ә кызы белән оныгын үзе пропискага кертсә ярамыймыни? Кияү агы ике бүлмәле фатирда берничә кеше яши. Ананы үгетли алмадык, ул кияве белән кызын талаштырып, аерылышырга мәҗбүр итте, бала ятим калды.

Яшерен никахлар хакында да әйтми кала алмыйм. Яшьләр әти-әниләре белән киңәшми генә никахлаша да, бер-берсен ошатмый башлап, аерылыша. Уку йортларындагы шәкертләр арасында булган хәлләр бу. Өч мәртәбә "талак" әйтәләр дә, җиңел генә кыз баланы ташлап китәләр. Бу хәлләргә йөрәгем бик әрни. Монда егетләрнең дә, кызларның да гаебе тигез, әлбәттә. Егетнең "яратам" дигән коры вәгъдәсенә генә ышаналар да, яшерен никах укытып, әти-әниләренә әйтмичә яши башлыйлар. Менә шуңа күрә мәдрәсәләрдә гаилә, никах, әхлак мәсьәләләренә күбрәк игътибар бирергә, дәресләр укыта башларга кирәк.

***—Ни өчен ир-егетләр генә түгел, кайбер сөйкемле затларыбыз да хыянәткә тартыла икән? Сезнең бу хакта уйланганыгыз бармы?***

—Бу мәсьәләгә кагылышлы сораулар белән миңа бик еш шалтыраталар. Бер ханым: "Мәктәпкә балаларны илткәч, беренче мәхәббәтемне очраттым. Хәзер гел шуны уйлап яшим. Яшь чактагы хисләрем уянды. Мин гөнаһлымы?"—дип киңәш сорады. Мин аңа гаиләне саклап калырга киңәш иттем. Ул иргә бу хатын кирәкми. Чөнки ул аның насыйбы булса, яшь чагында өйләнеп, гаилә корган булыр иде. Хәзер аның да гаиләсе, балалары бар. Бу ханымның да ире яхшы кеше, балалары бар. Кыскасы, ул хатын мине тыңлады.

Йөрәктәге хисләр кешене тайгак юлга да алып кереп китәргә мөмкин. Шуңа күрә акыл хисе белән яшәргә тырышсыннар иде. Бер минутлык хис-ләззәт өчен нигә гаиләне бозарга? Җимерү тиз булса да, кабаттан төзү—бик кыен эш.

***—Танышу агентлыклары, интернет аша танышу модада, хәтта кавышучылар да бар. Мондый парларның никахлары нык була микән?***

—Аллаһы Тәгалә бәндәләрне тудыргында, пар булсыннар дип, ир һәм хатыннарның санын тигез итә. Бу—Аллаһы Тәгаләнең кодрәте. Шушы кодрәтнең үтәлеше өчен сәбәпчеләр бар. Алар—яучылар, гаилә кору үзәкләре. Әгәр аралашкан кешеләрнең икесе дә камил акыллы икән, интернет та булырга мөмкин. Ләкин интернет—виртуаль тормыш бит ул. Анда кеше үзенең яхшы якларын арттырырга да мөмкин, ялган белән үзен яраттыру мөмкинлеге зур. Интернет аша танышып нык гаилә коручылар саны аз. Шуңа да мин интернет аша кавышырга теләүче яшьләргә сак булырга киңәш итәм. Синең "принц" дип сайлаган парың кеше үтерүче, куркыныч җинаятьче булып чыгарга да мөмкин бит.

Җәмгыятьнең әхлагы түбән, хәзер олы яшьтәге мөселман хатыннары яшь егетләр эзләп йөри. Үз яшендәге кеше кирәкми аларга, нәкъ менә яшь кеше кирәк. Югыйсә, алар—дин тотып, мөселман тормышы белән яшәүчеләр. Бик ямьсез күренеш бу, шулай булса да әйтми дә кала алмыйм. Ә яшь кызларга бай егетләр кирәк. Хәзер кеше авырлыктан курка. Генерал хатыны буласың килсә, лейтенантка кияүгә чык, диләр бит. Гарнизоннан гарнизонга йөреп, авырлыкларны бергә үтеп, тормышыңны бергә булдыр дигән сүз бу. Юк, яшьләргә менә бүген, хәзер үк һәм күп күләмдә кирәк.

***—Наилә ханым, Сез иregез белән ничек, кайда таныштыгыз? Ничә ел бергә яшисез?***

—Аллаһының рәхмәте белән, егерме ел бергә яшибез. Мәдрәсәдә таныштык без. Мин "Ислам динен кабул итүгә 1000 ел" исемендәге мәдрәсәгә укырга килдем, ул анда шәкерт иде. Миңа күп тапкырлар очрашырга тәкъдим ясады ул, тик "мин укырга дип килдем" диеп, гел каршы килдем. "Бу кыз минеке булырга тиеш",—дигән максат куеп, арттан бер дә калмый йөреп, үзенә карата белде. Шулай итеп кавыштык, Аллаһының рәхмәте белән ике улыбыз бар. Яшь чакта миңа бай егетләр дә күз салып йөрде, ә мин җаны бай булган кеше кирәк дип сайладым. Минем бөтен теләгем: " И Ходаем, миңа намазлы кешене насыйп ит",—булды. "Икебез бергә синең алдыңда гына башыбызны исәк иде",—дип сорый идем.

Ул вакытта намаз укучылар сирәк иде. Акыллы, әйбәт кешеләрдән: "Ә сезнең намаз укырга теләгегез бармы?"—дип сораганым булды. Алар: "Олыгайгач",—дип җавап кайтара иделәр. Берәү дә белми—олыгаерга өлгерәсеңме, юкмы? Күпме гомере барлыгын белә аламы берәребез? Шуңа күрә олыгайганны көтмәскә, намазлы буларга кирәк. Минем теләгем кабул булды, Аллаһы Тәгалә миңа намазлы бәндәсен насыйп итте. Үземне бәхетле хатын дип саныйм.

***—Тормыш ике полосадан тора, диләр—ак һәм кара. Менә шул кара полосалар аз булсын өчен ниләр эшләргә кирәк икән соң?***

—Тормыш һәрвакытта да бәйрәм була алмый, шатлыкларын да күрсәтә ул, сынауларын да бирә. Гөнаһлар кылмаска, Аллаһ кушканнарны үтәргә, тыйганнарыннан тыелырга һәм һәрвакыт догада булырга кирәк. Мин иртән торуга догасыз бер адым да атламыйм. Иң элек бу көннең хәерле булуын сорыйм. Чөнки доганың әһәмияте, көче бик зур. Адәм баласы дога белән генә бәхетле була ала. Әгәр догада булсаң, Аллаһы Тәгалә ни сорасаң шуны бирә. Менә син әйткән кара полосаны үтәргә дә көч бирүче—Аллаһы Тәгалә генә. Һәрвакытта да Аллаһы Тәгаләгә сыенып яшәргә кирәк.

***—Ир—хатынын, хатын ирен гомер буе яратсын өчен нидер эшләргә кирәкме? Әллә бу алдан язылган сценарий буенча куелган тормыш спектакле булырга тиешме? Ягъни, ир белән хатын берберсеннән туймасын, бер-берсенә тартылып торсын өчен хисләр уртаклыгы кирәкме, әллә инде акыл өстенлегеме?***

—Ир белән хатынның гомер буе берберсен хөрмәт итеп яшәве—хезмәт ул. Яшь чакта хисләр идарә итә, билгеле. Әмма акыл хисләре идарә иткән гаилә нык, гомерле була. Чөнки яшь чактагы хисләр юкка чыгарга да мөмкин бит.

Яшьлектәге хисләр—кешедәге бик тиз юкка чыгарга мөмкин булган эчке халәт. Ә акыл хисләре—тәрбия дигән сүз. Син гаиләне ничек сакларга, ничек алып барырга кирәклеген аңларга-белергә тиешсең. Ирең синнән разый булсын өчен ниләр эшләргә? Иреңнең характерын өйрәнергә, синнән нинди сүзләр ишетергә тели—шуларны әйтергә, ул яраткан кешеләрне хөрмәт итәргә кирәк. Шушы кагыйдәләрне белсәң, синең тормышың җайлы барыр. Син яхшы булган саен, ирең дә сиңа яхшылык белән җавап бирер. Һәрвакыт яхшы уйда булырга, әйләнә-тирәндәгеләргә яхшылыклар эшләп яшәргә кирәк. Синең эчке халәтең нинди, тормышың да шундый була дигән сүз. Үзең өстендә һәрвакыт эшләргә, үзеңне тәрбияләргә кирәк.

***—Бәхетле гаилә төзү өчен берәр рецепт бармы?***

—Һәрбер гаилә үзенчәлекле, бер-берсенә охшамаган. Чөнки кешеләрнең характеры бертөрле түгел. Берәүгә килешкән киңәш икенче гаиләгә зыян салырга мөмкин. Әмма, бөтен гаиләләргә дә ярый торган бер киңәш бар: бер-берегезне ярата белегез. Шундый итеп яратыгыз: синең ратканыңны парың һәрвакыт сизеп торсын. Нинди генә авырлыклар килсә дә, синең яныңда булырыңа ышанычлы булсын. Болар бик әһәмиятле. Бер-береңә булган ышаныч мәхәббәтне арттыра, еллар узган саен ул хисләр хөрмәткә әйләнә. Бер-береңне хөрмәт итеп яшәгәндә, бернинди язмыш сынаулары да кешене сындыра алмый.

*Гаиләне кору, саклап калу, мөселман хатын-кызларын эшкә урнаштыру кебек изге эшләр белән беррәттән, дизайнерлар хезмәте белән дә шөгыльләнә бу цзәк. “Сер түгел, хатын-кызлар кияүгә чыккач үзләренең тышкы кыяфәтләренә игътибарларын киметәләр,—ди Наилә ханым.—Ә ул иренә көн саен серле табышмак булып калырга тиеш. Ир хатынын күрергә, аның янына кайтырга ашкынып торсын. Ә моның өчен тышкы кыяфәтеңне, йорт эчен даими матур тотарга кирәк. Матур кием киеп, тәмле ашлар пешереп, йорт эчен пөхтә тоткан хатын янына ашкынып кайта ир кеше”,—дип, алтын киңәшләрен бирде ул. Шушыларны истә тотып, дизайнерлар киемнәр өстендә эшли икән. Киләчәктә хатын-кызлар өй эшләреннән бушагач, юудан төсе уңып беткән халатларын салып, матур күлмәк киеп куярга да өйрәнерләр әле болай булгач.*

*Әңгәмәгез өчен Аллаһының рәхмәте булсын Сезгә, Наилә ханым. Тормыш дигән озын, авыр юлны бер-берләренә таяныч булып, хөрмәт итеп, гафу итеп, юл куеп үтәргә Аллаһы Тәгалә һәр гаиләгә сабырлыклар бирсә иде. Амин.*

**Лилия ГАЛИЕВА**



Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ

***Татарстанның Баш казые***

# НИКАХЛЫ ГАИЛӘ ТАРКАЛМАС

***Әбү Бәкер (р.г.)нең әйткән сүзе бар: “Аллаһны танымаган, хәрәм белән хәләлне аермаган, изге гамәлләр кылмаган кешегә Аллаһның иң беренче җәзасы—дөньяда юлдан язган бала булыр. Ата-ананың төрле юллар белән тырышып-тырмашып җыйган байлыгын туздырыр өчен, картлык көнендә бөтен тынычлыгын алыр өчен шушы бер бала җитә, шушыннан артык бернәрсә дә кирәк түгел”.***

Әгәр без, Аллаһны танымыйча, теләсә нишләп йөрсәк, Аллаһы Тәгаләнең безгә игелексез бала бирүе бар. Безгә җәза бу. Һәм инде, киресенчә, хәрәмгә катышмыйча, изге гамәлләр кылып, тормышның авырлыкларына сабыр итеп, үзебезне кешечә тотсак, хайван дәрәҗәсенә төшмәсәк, безгә Аллаһы Тәгалә бүләк иттереп изге, миһербанлы бала бирер.

Гаилә ничек яши, никахның ныклыгы нинди—киләчәгебез шундый. Никахларыбыз төзек булмаса, аны игътибарга алмыйча яшәсәк, без хайван шикелле гомер иткән булабыз һәм үзебездән соң да юньле буын калдыра алмабыз. Балаларыбызның үзебездән начар булуы ихтимал. Әмма начар холыклы әти-әнинең дә баласы, әти-әнисенең хаталыкларыннан азат булып, яхшы бала булып үсәргә мөмкин. Әти-әнинең бурычы—тәрбияле бала үстерү. Әти-әнисе тау-тау алтын, бәллүрләр җыярга, берничә катлы өйләр салырга мөмкин, әмма баласында мәгънә булмаса, ул кеше картаймыш көнендә бәхетсез бәндәгә әйләнер. Баласының холкын алыштырыр өчен бөтен байлыгын бирер иде, әмма ул моны эшли алмый. Шуңа күрә гаилә, бала тәрбиясе беренче урында булырга тиеш. Аннан соң гына байлык турында уйла. Без бүген байлык тупласак, балаларыбызга рухи тәрбия бирмәсәк, нинди дә бер югарылыкка ирешербез дип өмет итәргә дә кирәкми.

Аллаһы Тәгалә бар нәрсәне парпар итеп яраткан, адәм балаларына да пар булып яшәүне фарыз дәрәҗәсенә куйган. Адәм баласы, үзенең тиңен табып, парлы булып яшәргә тиеш. Һәм, әйткәнемчә, үзенә караганда яхшырак, изгерәк балалар калдырырга лязем. Адәм баласының бу дөньяда төп вазифасы шул: үзеннән соң тәртипле, тәрбияле буын калдырырга тиеш.

Никах—Аллаһы Тәгалә каршында иң күркәм, иң саваплы, иң кирәкле гамәл. Никах—ул Аллаһы Тәгалә каршында, шаһитләр каршында бер-береңә “Аллаһ кушканча яшәрбез” дип вәгъдә бирү, бер-береңнең һәм әти-әниеңнең ризалыгы белән яши башлау. Әгәр ир белән хатын тормышларын Аллаһ кушканча көйли алсалар, бу никахның нәтиҗәсе игелекле бала булачак.

Бер генә гаилә нигезен дә, дәүләтне дә аракы ныгытканы юк. Аракы эчеп, теләк теләп берәүнең дә уңганы юк. Аракы—бозыклыкларның анасы. Һәм без, шушы никах көнне—гаилә кавышкан көнне, бозыклыкның иң начарын эшләп, “сез әйбәт торыгыз”, дип теләк телибез. Бу бит бер кысага да сыймый! Кешеләр, әлбәттә, никахсыз да яши алалар. Хайваннар никахсыз яши бит. Никах укымыйча да балалар үстереп була. Хайваннарның балалары, үсеп җиткәч, әти-әнисен оныта, аларны кадерләми. Никахсыз яшәсәк, йә булмаса, никахыбызга хилафлык китерсәк, бу балаларыбызның да үсеп җиткәч безне онытуына, хөрмәтләмәвенә, кадерсезләвенә китерә. Никахка салкын карау, никахсыз яшәү—киләчәк буын алдында җинаятькә тиң. Кем бүген ирекле мәхәббәт турында сүз алып бара, гаиләнең, никахның әһәмиятен киметергә тырыша, ул кеше—милләтнең киләчәгенә балта чабучы. Шуңа күрә адәм баласының күз карасыдай саклый торган гадәте никах булырга тиеш. Ул үзенең никахына тугры булырга, аны бозмаска, хыянәт итмәскә тиеш. Без балаларыбызны никахка җитди иттереп әзерләргә, үзебез дә никахыбызга хилафлык китермичә, аңа тугры булып яшәргә тиешбез.






*Сорауларга Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВ җавап бирә.*

***“Хиҗаб нинди таләпләргә җавап бирергә тиеш?”***

—Бит һәм кул чукларыннан кала, башны һәм тәнне тулаем капларга;
—Тәнгә сыланып тормаска;
—Үтә күренмәле булмаска;
—Күзгә ташланып тормаска тиеш.

***“Мин—мөслимә, намаз укыйм, хиҗаб киям. Ислам дине модага нинди мөнәсәбәттә, шуны беләсем килә.”***

—Киемгә кагылышлы мода турында сүз бара икән, мөслимәләр хиҗаб астыннан ничек тели, шулай киенә ала. Ләкин хиҗабны модага ияреп үзгәртеп кию—тискәре күренеш. Әгәр мода артыннан куа башлыйбыз икән, мөслимәләребез чишенеп бетәчәк, хиҗаб инде үз функцияләрен үтәми башлаячак. Ягъни, хиҗаб тәнгә сыланган, үтә күренмәле булачак. Ни кызганыч, мондый киемле мөслимәләрне бүген үк очратырга мөмкин. Андыйларга хиҗабның билгеле бер таләпләргә җавап биргән очракта гына хиҗаб булачагын тагын бер кат искәртеп үтәбез.

***“Хатын-кыз гәүдәсенең тубык сөягеннән түбән өлеше гаурәт саналамы?”***

—Намаз укыганда гаурәт саналмый. Әгәр хатын-кыз мәчеткә керсә, урамга чыкса яки башка җиргә барса, ул тубык сөягеннән түбән өлешне капларга тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: “Хатын-кызлар күрсәтергә ярагannардан (йөз белән куллардан) башка зиннәтләрен күрсәтмәсеннәр”,—ди (“Нур” сүрәсе: 31нче аять).

***“Зинһар, хиҗабның файдасын аңлатыгыз әле.”***

—Хиҗаб хатын-кызның һәм аның гаиләсенең абруен, намусын саклый.

Чит ил фильмы мисалында бер күренешне анализлап карыйк.

Ир эштән кайта. Хатыны аны ертык халаттан (ярамаган тагын иргә!) каршы ала. Ярый әле битенә крем сөртмәгән. Шулай да, йокларга ятканда һичшиксез битенә крем ягып, өстенә кат-кат киви, банан, помидор тезәчәк әле ул. Ә иртән эшенә бизәнеп-ясанып, кыска итәк киеп китә. Эштә, әлбәттә инде, аңа яшь егетләр тарафыннан игътибар да зур була, шаярып сүз дә кушарга мөмкиннәр.

Ир дә иртән торып эшкә бара. Ә анда... берсеннән-берсе чибәр кызлар һәм ханымнар. Игътибар итмәскә тырыша ул, билгеле. Ләкин, өендә аны ни-нәрсә көткәнен исенә төшерүгә...

Сезнеңчә, бу гаиләнең күпме гомере калган? Бу гаилә инде төзелеп бетмичә үк җимерелүгә бара. Икенче яктан караганда, мондый яшәү рәвеше алып барган хатын-кыз үзен файдаланып була торган объект итеп күрсәтә. Аңа ир-егетләр тарафыннан нәкъ шундый мөнәсәбәт булачак.

Игътибар итегез әле, сәхнәдә бүген кемнәр чишенә?! Тәннәреннән кала берни юк бит аларда! Кайда монда дәрәҗә, намус дигән төшенчәләр?! Хатын-кызларга шул кирәкмени?

Хиҗаб кигән хатын-кызның үзен тотышын карагыз. Күпләр, әгәр кыз хиҗаб ябынган икән, димәк, матур итеп киенә белми, дип фикер йөртә. Һич юк, бу кыз кыска итәк тә кия, күз явын алырлык итеп бизәнә дә ала. Ләкин аның матурлыгы бары үзенең гаиләсе өчен генә, чит-ят күзләр моны күрергә тиеш түгел.

Көнчыгыш көйләренә биегән кызларның киемнәрен һәркемнең күргәне бардыр. Көнчыгыш илләрендә яшәүче мөслимәләр ул киемнәрне кими дип уйлыйсызмы? Кияләр, тик бүтәннәргә күрсәтер өчен түгел.

Ирне өендә чибәр хатыны каршы ала икән, ул башка хатын-кызлар хакында уйлап та карамаячак. Гаилә дә нык булачак.

Башына яулык япкан, Ислам кушканча киенгән мөселман хатын-кызы Аллаһы Тәгалә каршында үзенең хакын үти. Өстәвенә, хиҗаб хатын-кызны яман күзләрдән саклый, медицина күзлегеннән караганда да файдасы бик зур.

***“Кыямәт көне җәзасыннан куркып та, яулык ябарга әзер булмаса, кыз кеше хиҗаб киюне берникадәр вакытка кичектереп тора аламы?”***

—Бүгенге көндә күпләр—ир-егетләр дә, хатын-кызлар да, Аллаһ кушканнарны үтәү хакында сүз чыкса: “Әзер түгел әле без”,—диләр. Әйдәгез, ачыклык кертик: ничек инде әзер түгел? Бу сорауны үзегезгә үзегез биреп карагыз.

Күз алдына китерик, сез—бер оешма җитәкчесе. Иртән эшкә килдегез һәм ишегалды себерүченең үз эшен башкармаганлыгын күрдегез, ди. Сез, билгеле инде, аңа карны күрәргә, ишегалдын җыештырырга кушасыз, ә ул: “Гафу итегез, мин әзер түгел”,—дип җавап кайтара. Көлке җавап, әлбәттә.

Менә бу—кешеләр арасындагы мөнәсәбәт. Җитәкче үзенең хезмәткәренә, хезмәткәр җитәкчесенә кул да, аяк та бирмәгән... Ул гына да түгел, җитәкче, хезмәткәренең үзе кебек үк үләсен белсә дә, буйсынмаганы өчен җәза бирәчәк.

Аллаһы Тәгалә безгә куллар, күзләр, чәчләр биргән, безне тәэмин итә, һава, кояш өчен салым түләргә дә мәҗбүр итми. Ә кешеләр Аның кушканнарын үти алмый. Гәрчә Ул кушканнарны һәркем үти алса да. Әгәр оешмада эшләүче хезмәткәргә, Аллаһ сакласын, берәр нәрсә булса (кулын өздерсә, сукырайса һ.б.), аны эштән куачаклар. Һәм оешма җитәкчесе аның киләчәк тормышы белән кызыксынмаячак та. Безгә тән биргән, тәэмин иткән, һәрвакыт туры юл күрсәтүче Аллаһы Тәгалә, кешегә ни генә булмасын, ярдәменнән ташламаячак. Ул—Мәрхәмәтле. Ул безгә биргән тән хакында уйлаганыгыз бармы сезнең? Безгә бит аның өчен җавап тотарга кирәк булачак. Әйе, Аллаһка буйсынырга мы, юкмы—сайлау хокукы бар. Ләкин һәр сайлау өчен һәркем җавап тотачак. Аллаһы Тәгалә Үзенә буйсынган кешене бу дөньяда рәхмәтеннән ташламас (Аллаһ кушканнарның барысы—Аның кешелек өчен рәхмәте), аннан соң булачак дөньяда да шулай ук. Ә буйсынмаучылар—чынлап та бу дөньяда бәхетсез кешеләр (хәтта алар матди яктан 100% тәэмин ителгән булса да). Әгәр бу хәлдә үлсә, ахирәттә дә бәхетсез булачак алар. Әгәр кеше Аллаһының бүләген файдаланмый икән, Ул аны бу нигъмәттән мәхрүм итәргә дә мөмкин.

Югарыда әйтелгән дәлилләрдән соң, “Мин әзер түгел”,—дигән җавапның урынсыз икәнлеген аңлагансыздыр.

**Сездән—сорау, бездән—җавап**

***Дини һәм көнкүреш мәсьәләләренә кагылышлы сораулар буенча белгечләрдән консультация алырга мөмкин.***

**Телефон: (843) 279-08-32.**
**Юридик консультация бирү бүлеге.**

**Кабул итү көннәре:**

**Шәүкәт хәзрәт ӘБҮБӘКЕРОВ.**
Дүшәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә 17.00-18.00 сәгатьләрдә.

**Адвокат Руслан НАГИЕВ.**
Сишәмбе, җомга көннәрендә 17.00-18.00 сәгатьләрдә.

## Әти-әниләргә



# Ислам диненә мәхәббәт тәрбиялик

Балага дин кирәкме? Әлбәттә! Кешенең күңеленә “дин” дигән орлыкны салу өчен иң кулай вакыт—балачак. Чөнки әле бу вакытта балада фәрештә сыйфатлары өстенлек итә. 7 яшькә кадәр Аллаһка мәхәббәт формалашкан булырга тиеш. Әгәр без кечкенәдән дөрес тәрбия бирә алсак, дин—аның өчен үзе белән бергә дөньяга килгән һәм үлгәнче алып барасы хакыйкать. Ул инде динсез яшәүне күз алдына китерә алмаячак. Шуңа күрә һәр әти-әни, соңга калмыйча, баласына Ислам дине кыйммәтләрен төшендерергә тиеш. Әмма балага Ислам диненә мәхәббәт тәрбияләү белән бергә, башка диндәгеләрне дә хөрмәт итәргә өйрәтү зарур. Аллаһы Тәгалә: “Өйләрдән куып чыгармасалар, көчләп хәрәм ризык ашатмасалар, динең өчен сине кыерсытмасалар, алар белән тыныч яшәгез”,—ди.

Диннең төп бурычы—баланың югары рухи үсешен тәэмин итү. Рухи үсешнең ачкычы булып Аллаһны тану тора. Һәр эшне “Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим”не әйтеп башлатырга гадәтләндерү, иман кәлимәсен—“Ләәә иләәһә илләллааһү Мухәммәдүр расүүлуллааа һ”ны өйрәтү аеруча мөһим. Бала көн саен кимендә йөз мәртәбә: “Ләәә иләәһә илләллааһ”,—дип әйтергә гадәтләнсен. Шулай да, кечкенә вакытта балага артык күп гыйбадәтләр йөкләү урынлы түгел. Балага дөньяны таныту, табигатьне өйрәтү, фикерләү сәләтен үстерү юлы белән Аллаһка мәхәббәтне көчәйтергә һәм шуның нәтиҗәсендә әкрен генә фарызларны үтәргә гадәтләндерергә, хәрәмнән тыелырга өйрәтергә кирәк. Балигъ булгач кына өйрәтә башласак, соң булачак. Балага кечкенәдән: “Минем турыда уйлаучы һәм һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торучы, догаларымны ишетүче, кайгыларымны аңлаучы Зат—Аллаһ бар”,—дигән хакыйкатьне аңлата алган әти-әни иң зур тәрбия биргән булыр. Моны әти-әни генә түгел, балалар бакчасы тәрбиячеләре дә, укытучылар да аңласа иде.

Бала рәхмәт әйтергә дә гадәтләнсен. Ул нинди генә эшкә тотынса да, ахырына кадәр җиткерүен игътибарда тотарга, аңа бераз ярдәм дә итәргә кирәк. Нәтиҗәдә бала максатка ирешү юлында сабыр булырга һәм һәртөрле хезмәттән тәм табарга өйрәнәчәк.

Ихтыяр көче тәрбияләүдә фарыз гамәлләрнең йогынтысы да зур. Намаз—балага игътибарын тупларга, ураза—нәфесен тыярга, сәдака бирергә өйрәтү киң күңелле булырга ярдәм итә.

Хайваннардан аермалы буларак, кешегә җитлегү яшенә җиту өчен 17-18 ел гомер кирәк. Баланы тәрбияләү өчен Аллаһ безгә күпме гомер биргән. Әгәр шуны заяга үткәрсәк, кәфер нигъмәткә юл куючылар булырбыз, Аллаһ сакласын.



## БИСМИЛЛӘҺ

Әссәламегаләйкүм, нәни дустым!

Син матур сүзләр беләсеңме? Бүген без сине яңа матур сүз белән таныштырабыз.

“Бисмиллә һ” сүзен ишеткәнең бармы? Аны кайчан әйтәләр? Бу сүзнең мәгънәсен беләсеңме? Әйе, һәр эшнең башында “Бисмилләһир-рахмәнир-рахим” дип әйтергә кирәк. “Бисмилләһ” сүзе гарәп теленнән “Аллаһ исеме белән башлыйм” дигәнне аңлата. Мөселманнар һәр эшне Аллаһы Тәгалә исеме белән башлыйлар. Һәр эш алдыннан “Бисмилләһ” әйтик. Якын кешеләребезгә матур сүзләр белән эндәшик, елмаеп карыйк, үзебезне тәртипле тотыйк.

## Иманлы бала



## Хикмәтле сүз

Рәсимә белән Рәсилә—игезәкләр, икесе дә бакчага йөриләр. Аларга алты яшь тулган көнне авылдан Дәү әниләре дә кунакка килде. Әниләре бик тәмле торт пешергән иде, кызларның авызлары ерылды.

—Кулларыгызны юыгыз да, өстәл артына рәхим итегез,—диде әниләре, кызлары өчен сөенеп.

Әтиләре икесенә дә бик матур курчаклар алып кайткан. Аларны да күргәч, кызлар тагын да сөенештеләр. Курчакларын да алып өстәл тирәсенә елышты кызлар. Күпереп пешкән, җиләкле тортны ашарга үрелгәндә генә, Дәү әниләре:

—Балакайлар, бисмиллагызны әйттегезме соң әле?—дип сорады.

Рәсимә: “Бисмилләһир-рахмәнир-рахим”,—дип тортка үрелде. “Бүгенгә ярар инде”,—дип уйлаган Рәсилә, бисмилласыз торт кисәген авызына озатты...

Бик яман кылкынган кызлары Рәсиләне күреп котлары алынган әти белән әни тиз генә Ашыгыч ярдәм чакырдылар. Алар килгәнче, Дәү әниләре тиешле ярдәмне күрсәтеп, баланы тынычландырган иде инде. Дәү әнисенең дога укыйукый сыпыруыннан тәмам изрәгән бала, назланып сыенды да:

—Дәү әни, гафу ит инде, яме, мин “бисмиллә һ” әйтмәгән идем бит,—дип пышылдады.

Дәү әнисе елмаеп, оныгын күкрәгенә кысты да, башыннан сыйпый-сыйпый:

—Мине алдап булган кебек, Аллаһы Тәгаләне алдап булмый шул, балам. Ул барысын да күреп, белеп тора. Икенче алай эшләмә,—диде.


...Бераздан бәйрәмне дәвам иттеләр. Күп теләкләр әйтелде. Әмма кызларның күңеленә сеңеп калганы: “Хәләл ризыкны да бисмилласыз ашамагыз, балалар”,—булды.

**Мөнирә САФИНА**


## Табышмак әйтәм, җавабын тап!

Җәеп нәни паласымны
Торгызамын намазымны.

(Намазлык)



## Рәсемне буя.



# НАМАЗГА БАСКАЧ, НИ ҮЗГӘРДЕ?

***Намаз укучы—Аллаһы Тәгаләгә иң якын кеше була, диләр. Танышларым арасында намаз ияләре шактый. Күбесе пенсия яшенә җитмәгән әле, икешәр эштә эшлиләр, балалар укыталар... Мин алардан: “Намазга баскач, нинди үзгәрешләр булды?”—дип сорыйм. Барысы да: “Яхшы якка гына”,—диләр.***



**Венера апа** *(укытучы):* “Иртәнге намазны укый башлагач тойган рәхәтлекне әйтеп аңлатып бетереп булмый, көне буена җитәрлек энергия алам. Әлек мәктәптән бик арып кайта идем, хәзер үземне яшьләрчә тоям”.

**Әлфинә** *(сатучы):* “Намаз укый башлагач, кайбер вак-төяк гөнаһларны эшләргә курка башладым. Кешедән алып калганчы, брак, черек аркасында килеп чыккан җитмәүчәнлекне үз кесәңнән түләү яхшырак икәнлегенә төшендем. Һөнәремне алыштырырга соңга калсам да, намазга басарга соңламадым, Аллага шөкер”.

**Мәдхия** *(идән юучы):* “Йортыбызга тынычлык инде, Аллага шөкер. Моңа минем намазга басуым сәбәп булды, үземне сабырлыкка өйрәттем.

Гауганы хатын-кыз үзе чыгара бит. Шат чырайлы кешеләр күбрәк булсын иде дигән теләктә калам”.

**Мәсхүдә** *(клуб мөдире):* “Намазга баскач, күзлек кими башладым. Иң гаҗәпләндергәне шул булды”.

**Хәмит** *(физкультура укытучысы):* “Намазны карчык белән икәү бергә укыйбыз. Мәктәптән ашыга-ашыга кайтам да намазлыкка басам. Бөтен арыганнар юкка чыга, ачулар тарала, яңадан туган кебек булам. Пенсиягә чыккач, дини юлдан тайпылмаска исәбем. Шәһадәтнамәм дә бар, балаларны өйрәтермен, кирәк булса, имам вазифаларын да башкара алам. Намаз укымаучы кешеләрне иң-иң бәхетсез җаннар дип саныйм, үзләрен нинди рәхәтлектән мәхрүм итәләр бит! Намазга басучылар саны тагын да артсын иде дип телим, авырмый гына яшисе иде”.

**Зөфәр хәзрәт Тәхавиев** *(“Гафиятулла” мәчете имам-хатыйбы):* “Аллаһы Тәгаләгә ышанучының иң зур гаебе—Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылмавы һәм намаз укымавы. Чөнки намаз—Аллаһы Тәгаләнең хакы. Кем бу хакны хаклый, димәк, ул кеше Аллаһы Тәгаләнең иң зур зекерен, иң зур хакын хаклый. Кем бу хакларны хакламый, ул кеше Аллаһы Тәгаләнең хакларын хакламаучы, Аңа карышучы, Аңа каршы баш күтәрүче була. Әлмисактан (җаннар яратылган вакыт) Аллаһы Тәгалә белән адәм балалары арасында төзелгән шартнамәне, антны, вәгъдәне бозучы була. Намаз уку—Аллаһы Тәгаләгә коллык күрсәтү. Кеше Аллаһы Тәгаләгә генә кол булырга тиеш, кеше кешегә, мәхлукка, малга кол булырга тиеш түгел!”

*Укыган намазларыгыз савапка булсын! Барчабызга да акыл белән, саф тойгылар белән яшәргә насыйп булсын. Амин!*

**СӘРВИНАЗ**

# “Гаилә” Ислам-Мәдәни Үзәге” региональ җәмгыять оешмасы ачылды

Нык һәм сәламәт гаилә—бәхетле җәмгыять төзү өчен төп нигез. Гаилә—ул җәмгыятьнең йөрәге. Шуңа да Ислам дине гаиләгә кагылышлы сорауларга, аны саклау һәм яклау кагыйдәләренә зур игътибар бирә. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ир белән хатын мөнәсәбәтләрен дә матур итеп сурәтли. Аллаһы Тәгалә: “Үзегездән хатыннарны яратуда, ул хатыннар белән бергә яшәвегез дә, ир белән хатын арасындагы мәхәббәт һәм наз, бербереңнең хаталарын кичерә белү, һичшиксез, Аллаһның кодрәтенә ачык дәлилләрдер. Хактыр ки, бу эшләрдә фикерли белүче кавемнәр өчен гыйбрәтләр бар” (“Рум” сүрәсе: 21нче аять),—дигән.

Аллаһ безне гаиләгә Үзенең олы нигъмәте итеп карарга өйрәтте. “Аллаһ арагыздан хатыннар яралтты, хатыннарыгыздан угыллар, оныклар яралтты вә сезне саф азыклар белән ризыкландырды” (“Нәхел” сүрәсе: 72 нче аять),—дигән Аллаһы Тәгалә.

“...Игелек итүдә, яман эш кылудан саклануда бер-берегезгә ярдәмләшегез. Гөнаһ кылуда, дошманлык эшләрендә ярдәмләшмәгез. Гөнаһлы булудан, Аллаһ каршында җавап бирүдән куркыгыз. Аллаһның җәзасы бик тә хәтәр булыр” (“Маидә” сүрәсе: 2нче аять)

Аллаһының ярдәме белән без, беренче максаты дин аша гаиләне, кешеләкне саклау булган Оешмага берләштек. Гаилә—ул бер дәүләт. Ә дәүләт төзек булсын өчен, аның ныклы терәге булырга тиеш. Бүгенге көндә таяныр бердәнбер әйбер—Ислам дине. Җәмгыятьне бозылыктан, кешеләрне караңгылыктан чыгару юлы да—дин генә. Теләгебез—гаиләләрне саклап калу, ир һәм хатын, балалар белән мөнәсәбәтләрне җайлау. Безнең оешма гаиләгә кагылышлы барлык сорауларны Ислам дине кануннарына нигезләнеп, Аллаһы Тәгалә кушканча чишү юлларын эзли.

Үзәктә гаиләнең дини яктан аң дәрәҗәсен үстерү, дини һәм юридик консультация бирү, уку-укыту, хәйрия, мәдәни-күңел ачу, нәшрият, медицина, мәгълүмати бүлекләр уңышлы эшләп килә.

Изге күңелле мөселманнарны безнең Оешманың әгъзасы булырга чакырабыз.

# СКАНВОРД




Дөньяга караш

Күпчелек пәйгәмбәрнең һөнәре

Хаҗның фарызы

“Игрик”ның иптәше

Сыпыру

Сабыйлар ризыгы

“Изге ... — иманның яртысы”

Фото №2

Тәңкә

Якын кеше

Ихрамга керү урыны

Гарәп язуында өздерү билгесе

Үләвә

Ышану

Хаҗның фарызы

Аркылы

Фото №2

Ислам динендә булучы

Аллаһның куныгы

Мусаның таягы шуңа әйләнә

Җәннәт ачкычы

Материк

Хаҗ йолаларын үтәү урын

Карт

Мәетне озату

Гаилә башлыгы


Ир-ат исеме

Әтинең әнисе

Намазга чакыру

Кечкенә

Ил исеме




Газетаны www.islamsemya.ru сайтында укый аласыз.

Газета Татарстан Республикасы “Гаилә” Ислам-Мәдәни Үзәге” региональ җәмгыять оешмасы тарафыннан нәшер ителә.

www.islamsemya.ru
Телефон: (843) 279-08-32.
Тираж: 5000.

Әлеге басманы нәшер итүдә катнашып, сез хәйрия эшләренә өлеш кертәсез

420088, Казан шәһәре,
2нче Азино урамы, 1В йорты.
Телефон/факс: (843)279-13-94
ИНН 1660163116 КПП 166001001
р/с №40703810200100000022
к/с 30101810900000000798
БИК 049205798
АКБ “БТА-Казань” (ОАО) г.Казань